Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**11 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның «11 » ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2022 елның «11 » ноябрендә 13 сәгать 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пункты террито-риясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакы-тлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен фай-далануга ризамы":

1. Бима торак пунктындагы Пролетар, Мәктәп, М.Горький урамнары өчен вак таш сатып алу һәм юлларны каплау (сатып алу һәм урнаштыру). Килешү буенча эш өчен түләү;

2. Бима торак пунктында үләннәр һәм чүп үләннәрен чабу (дизель ягулыгы һәм май алу);

3. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү(урамнарны кардан чистарту, дизель ягулыгы һәм май, запчастьләр сатып алу). Килешү буенча эш өчен түләү;

4. Бима торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонтлау, хезмәт күрсәтү, су белән тәэмин итү өчен башка материаллар сатып алу);

5. Янгын автомашинасын тоту, ремонтлау. Килешү буенча эш өчен түләү;

6. Бима торак пунктында урамнарны яктырту өчен лампалар һәм фонарьлар сатып алу, урнаштыру. Электрикка килешү буенча түләү;

7 Бима торак пунктында бензин триммеры өчен запчастьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу. Килешү буенча түләү;

8. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (алгы төягеч һәм әйләндергеч чапкыч);

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 362 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 195 кеше, бу – 54% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 195 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» Биматорак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш иректән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Бима торак пунктындагы Пролетар, Мәктәп, М.Горький урамнары өчен вак таш сатып алу һәм юлларны каплау (сатып алу һәм урнаштыру). Килешү буенча эш өчен түләү;

2. Бима торак пунктында үләннәр һәм чүп үләннәрен чабу (дизель ягулыгы һәм май алу);

3. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм  хезмәт күрсәтү(урамнарны кардан чистарту, дизель ягулыгы һәм май, запчастьләр сатып алу). Килешү буенча эш өчен түләү;

4. Бима торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонтлау, хезмәт күрсәтү, су белән тәэмин итү өчен башка материаллар сатып алу);

5. Янгын автомашинасын тоту, ремонтлау. Килешү буенча эш өчен түләү;

6. Бима торак пунктында урамнарны яктырту өчен лампалар һәм фонарьлар сатып алу, урнаштыру. Электрикка килешү буенча түләү;

7 Бима торак пунктында бензин триммеры өчен запчастьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу. Килешү буенча түләү;

8. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (алгы төягеч һәм әйләндергеч чапкыч);

9. Бима авыл клубы территориясен төзекләндерү, материаллар сатып алу. Килешү буенча эш өчен түләү.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы А.Г. Ишпаев

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет
Бимского
сельского поселения
Бима авыл
җирлеге Советы
ИНН 1601002621
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ